ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $6^3$ статьяның 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль район, шәһәр округы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны кимендә 500 берәмлек тәшкил итә;»;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне үзгәртә торган, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге**

1) Әгерҗе муниципаль районы;
2) Азнакай муниципаль районы;
3) Актаныш муниципаль районы;
4) Алексеевск муниципаль районы;
5) Әлмәт муниципаль районы;
6) Арча муниципаль районы;
7) Баулы муниципаль районы;
8) Балтач муниципаль районы;
9) Бөгелмә муниципаль районы;
10) Буа муниципаль районы;
11) Югары Ослан муниципаль районы;
12) Биектау муниципаль районы;
13) Алабуга муниципаль районы;
14) Зәй муниципаль районы;
15) Зеленодольск муниципаль районы;
16) Кукмара муниципаль районы;
17) Лаеш муниципаль районы;
18) Лениногорск муниципаль районы;
19) Мамадыш муниципаль районы;
20) Менделеевск муниципаль районы;
21) Минзәлә муниципаль районы;
22) Түбән Кама муниципаль районы;
23) Нурлат муниципаль районы;
24) Питрәч муниципаль районы;
25) Балык Бистәсе муниципаль районы;
26) Саба муниципаль районы;
27) Сарман муниципаль районы;
28) Тукай муниципаль районы;
29) Чистай муниципаль районы;
30) Чаллы шәһәре.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 февраль
№ 2-ТРЗ